**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 17 апреленнән — № 53-413

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне арендалау өчен түләү срогын билгеләү турында» 2024 елның 05 сентябренедәге 48-367 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә инвестиция эшчәнлегенә муниципаль ярдәм турында Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 14 июлендәге 287 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә, атарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне арендалау өчен түләү срогын билгеләү турында» 2024 елның 05 сентябренедәге 48-367 номерлы боерыгына (алга таба - Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «5 (биш) ел тәшкил итә» сүзләрен «8 (сигез) елдан артымый» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны вакытлы матбугат басмасында - «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасында https://novoshishminsk.ru, «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы — В. М. Козлов